СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2026 г.Лениногорск № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге №98 карарының кереш өлешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы»сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 30.07.2015 № 51, 30.03.2016 № 51, 27.12.2016 № 114, 30.05.2017 № 38, 08.08.2017 № 63, 15.11.2017 № 81, 19.01.2018 № 5, 29.03.2018 № 18, 27.09.2018 № 56, 13.12.2018 № 80, 06.02.2019 № 4, 23.10.2019 № 56, 21.02.2020 № 11, 12.11.2020 № 33, 26.03.2021 № 10, 06.08.2021 № 45, 20.05.2022 № 28, 03.03.2023 № 8, 10.08.2023 № 41, 17.10.2023 № 52, 14.12.2023 № 89, 24.04.2024 № 31, 04.10.2024 № 73, 27.11.2024

№ 89, 30.01.2025 № 3, 10.10.2025 №18 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар белән« сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләренә алмаштырырга.

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«9.1. Муниципаль хезмәт урынын биләүгә дәгъва кылучы гражданин, муниципаль хезмәткәр эш бирүче вәкиленә (эш бирүчегә) 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган очракларда керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыра. Әлеге мәгълүматлар 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшыру тәртибе, сроклары һәм формасы буенча тапшырыла.

Муниципаль хезмәт урынын биләүче муниципаль хезмәткәр, тиешле исемлеккә кертелгән, 2012 елның 3 декабрендә кабул ителгән 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән тәртип һәм форма буенча тапшырырга бурычлы.

3) 9.2 пунктында «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 9.3 пунктында «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге мәкаләгә туры китереп бирелә торган мәгълүматлар» сүзләре белән алыштырырга;

5) 9.4 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге мәкаләгә туры китереп бирелә торган мәгълүматлар» сүзләре белән алыштырырга;

6) 9.5 пунктында «үз керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» сүзләрен” 25 декабрь 2008

ел, № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон белән каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, һәм 3 декабрь 2012 ел, № 230-ФЗ «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон белән каралган чыгымнар турында мәгълүматлар» сүзләренә алыштырырга;

7) 9.9 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«9.9 Контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар, әлеге бүлекнең 9.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны тәкъдим итәләр, ә мондый вазифаны биләүче зат Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) мәгълүматларны тәкъдим итә»;

8) 10 бүлекнең 10.1.3 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«10) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар»;

9) 10.1.1 пунктының 10.1 пунктчасында, 17.1 пунктының 5 пунктчасында, 17.5 пунктында, 17.5 пунктының 17.5.4 пунктчасында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законы сүзләрен «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» сүзләре белән алыштырырга;

10) 17.5 пунктының 17.5.3 пунктчасында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсе сүзләрен «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы белән каралган нормалар» сүзләре белән алыштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

М.Н.Гирфанов